# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

чираттан тыш утырыш

**КАРАРЫ**

16 нчы февраль 2021 ел **№ 39** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының «Теләче муниципаль районы «Теләче» сәнәгать (индустриаль) паркы территориясендә үзләренә арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләвеннән үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны азат итү турында» 2014 елның 20 февралендәге 192 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Созидание» идарәче компаниясе ҖЧҖ генераль директорының 2020 елның 15 декабрендәге 174 номерлы, 2020 елның 23 декабрендәге 179 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 02 декабрендәге 984 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Советының «Теләче муниципаль районы «Теләче» сәнәгать (индустриаль) паркы территориясендә үзләренә арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләвеннән үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны азат итү турында» 2014 елның 20 февралендәге 192 номерлы карарына (район Советының 20.05.2015 ел №266, 01.02.2018 ел №120, 03.09.2020 ел №251, 09.10.2020 г. № 12 карарлары редакциясендә) үзгәрешләр кертергә:

1.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1. «Созидание» идарәче компаниясе - «Теләче» индустриаль (сәнәгать) паркы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять территориясендә җир кишәрлекләрен арендага алган өчен түләүдән 2013 елның 01 маеннан 2025 елның 31 декабренә кадәр азат итәргә, түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Теләче авыл җирлеге, Теләче авылы, Теләче муниципаль районы бюджетына күчерелү өлешендә Теләче муниципаль районының муниципаль милкендәге яисә дәүләт милке чикләнмәгән булган, түбәндәге категорияләрдәге юридик затлар өчен:

«Созидание» идарәче компаниясе - «Теләче» индустриаль (сәнәгать) паркы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять территориясендә үз житештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

- «Созидание» идарәче компаниясе - «Теләче» индустриаль (сәнәгать) паркы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять территориясендә корылмалар, продукция җитештерү объектлары төзү эшләрен гамәлгә ашыра.».

1.2. карарны 1.1 пунктны белән тулыландырырга, түбәндәге редакциядә: 2013 елның 01 маеннан 2025 елның 31 декабренә кадәр «Созидание» идарәче компаниясе - «Теләче» индустриаль (сәнәгать) паркы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять территориясендә сәнәгать паркы территориясен су белән тәэмин итү өчен скважиналар һәм су җыю башнялары урнашкан җир асты байлыкларыннан файдалану өчен лицензияләре булган Арендаторларны аренда түләвеннән азат итәргә. Түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджетына күчү өлешендә Теләче муниципаль районының муниципаль милкендә булган яисә дәүләт милке чикләнмәгән.»

2.Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы

Н.Н. Хажипов